А. С. Пушкин

ПОП һәм аның ялчысы Балда турында әкият

Александр Сергеевич Пушкинның тууына 200 ел

А. С. Пушкин

Поп һәманың ялчысы Балда турында әкият

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1998

А. С. ПУШКИН Поп һәм аның ялчысы Балда турында әкият



Бар иде, ди, бер поп,
Башы бар—акылы юк.
Китте, ди, поп базарга,
Нинди булса товар карарга.
Менә каршына Балда килә,

Үзе дә белми, кая килә.
"Ник иртә тордың, атакай,
Нәрсә эзләнәсең болай?"



Миңа, — ди поп, — кирәк бер ялчы:
Аш-сучы, ат караучы һәм балтачы.
Кыйммәт тә булмасын. Менә шундый
Ялчыны кайдан табарсың?" — ди.
Балда әйтә:
"Сиңа тырышып, әйбәт иттереп
Хезмәт итим җиренә җиткереп,
Маңгаеңа елына өч чиертү хакына.
Пешкән борай булыр ашыма".
Маңгаен кашып,
Уйга батты поп.
Чиертүнең бит төрлесе бар.
Тик шулай да, шаять, ди, эшем уңар.
Балдага поп: "Ярый, — дип әйтә, —
Икебезгә дә төшмәс кыйммәткә.
Яшә миндә, үтә йомышларымны,
Күрсәт ничек тырышканыңны!"
Шул вакыттан алып Балда
Яши попта, йоклый саламда.
Ашый дүртәү өчен,
Эшли җидәүнең эшен.
Таңнан ук бар эш ходка җибәрелгән,
Ат җигелгән,
Җир сөрелгән,
Мич ягылган,
Кирәге сатып алынган,
Күкәен дә пешергән,
Кабыгын да әрчегән.



Поп хатыны Балданы мактап бетерә алмый,
Поп кызының Балда сагышыннан тәкате
калмый.
Поп малае "әти" ди Балданы,
Ботка ашата чөнки, карый ул аны.



Балданы яратмый поп кына,
Аны иркәләми ул гына.
Вакыт җитә, якын көннәрдә
Хезмәт хакын кирәк түләргә.
Ашамый, эчми, йокыдан кала поп,
Маңгай чатнап тора алдан ук.
Серне ачып әйтә бикәгә:
"Эш шулай, ди, нихәл итәргә?"
Тапкыр була аның карчыгы,
Әйтерсең лә хәйлә капчыгы.
Әйтә: "Беләмен, ди, чараны,
Кире кагарга бездән ул бәлане:
Көче җитмәс эшкә куш аны,
Кушканыңча үтәсен ул шуны.
Шуның белән маңгаеңны коткарырсың,
Балданы да хак түләми озатырсың".
Попның күңеле күтәрелде,
Балдага ул туры карап көлде.

Кычкырды ул: "Гадел ялчым, Балда,
Кил әле минем алга!
Тыңла: гомерем буе миңа җеннәр
Оброк түләргә сүз бирделәр.
Бу шәп табыш булыр иде дә,
Өч ел инде, бирмиләр менә.
Бораеңны ашап бетер,
Җеннәрдән оброк җыеп китер".

Сүз кайтарып тормыйча гына,
Балда китте диңгез ярына.
Анда бау ишәргә тотынды,
Бау очын диңгезгә манчыды.
Менә карт җен чыкты диңгездән:
"Ни телисең, Балда, син бездән?"

Күккә асып куям диңгезне,
Кортам каһәр суккан нәселегезне".
Бу сүз җитә калды җен өчен:
"Мондый рәхимсезлек ни өчен?"
"Түләмисез чөнки оброкны,
Онытасыз куелган срокны!
Менә безгә булыр тамаша,
Сез этләргә бәла һәм каза".
"Балдакай, асма диңгезне, калсын,
Оброкны тулысы белән алырсың.
Малаемны чыгарыйм, көт бераз".
Уйлый Балда: "Бу тиз алданмас!"
Күп тә үтми килеп чыкты җен малае,
Ачка беткән мәче сыман мияулады:
"Нихәл, Балда-мужик...
Нинди оброк кирәк, тыңлап карыйк?
Бу турыда гомер ишеткәнем юк,
Җен башына мондый кайгы төшкәне юк.
Йә, ярый, алырсың. Тик, килешик,
Килешер өчен болай сүз бирешик:
Икәү диңгез тирәли йөгерик,
Кайсыбыз узар, оброкны шуңар түлик.
Йә, башлыйбыз, бу эш гадел булыр,
Шул арада капчык та әзер булыр".
Ышанмаган төсле кыланып:
"Чынмы?" — диде Балда, елмаеп.
"Кая сиңа минем белән куышырга,
Балданың үзе белән узышырга?
Җибәргәннәр, имеш, йөрәкле җенне!

Син көт әле минем энемне!"
Балда күрде якын урманны,
Барып тотты ике куянны,
Капчыкка салды да диңгез янына кайтты,
Анда җен малаен очратты.
Куянның берен ул колагыннан
тартып чыгара:
"Безнең кубызга биеп кара;
Ә син, җен кисәге, юкка көчәнмә,
Вакытыңны бушка үткәрмә
Минем үзем белән куышып, —
Энем белән кара узышып!
Бер, ике, өч! Калышма!"
Җен һәм куян менә чабыша:
Җен малае — диңгез ярына,
Куян китте урман ягына.
Менә бервакытны нык арып,
Хәлдән таеп, телен чыгарып,
Җен малае, диңгез әйләнеп,
Тирләп кайтты, теле бәйләнеп.

Узган, имеш! Ләкин, ни күрсен, —
Балда сыйпап ята "энесен"
Һәм сөйләнә: "Ардыңмыни? — ди. —
Инде бераз ял ит, энем", — ди.
Җен малае шаккатты,
Койрыгын кысып, бәбәген акайтты.
Кырын карап моның "энесенә",
"Оброкка" дип чумды диңгез эченә.
"Бабай, башлар харап булды, — ди, —
Энесе дә мине узды!" — ди.
Карт җен уйга батты.
Балда шундый тавыш кузгатты, —
Бөтен диңгез айкалды,
Дулкыннары чайкалды.



Яшь жен чыгып әйтте: "Җитәр сиңа,
Оброкны алырсың барысын да.
Тик кара әле менә бу таякка;
Шуны ыргытыйк теләсәң кай якка,
Кем ераграк җибәрер,
Оброк та шуңар түләнер.
Кулың каерылыр дип шүрлисең мәллә,
Ни көтәсең?" — "Болытны көтәм, әнә,
Таякны мин шуңар очырачакмын.
Бар җеннәрне пыр туздырачакмын".
Җен баласы куркып бабасына йөгерде,
Балданың җиңүен сөйләп бирде.
Өстә Балда тагын тавышлана башлады,
Җеннәргә бавы белән янады.
Җен баласы чыкты да болай диде:
"Җаның теләгәнне ал инде..."
"Юк, — ди Балда, —
Минем чират алда —
Инде мин куям шартны:
Күрәсеңме күк атны?
Көчеңне күрсәтче;
Шул бияне күтәрче,
Шуны күтәрсәң,
Ярты чакрым үтәлсәң, —
Оброк синеке;
Илтә алмасаң, — оброк минеке".
Шулай итеп яшь жен
Бия астына керде, мескен.
Кызарынды, бүртенде, көчәнде, —
Бияне күтәрде.

Ике адым атлап узды,
Өченчесендә егылып сыйракларын сузды.
Балда әйтә: "Син, юләр җен,
Нигә бия астына керден?
Син аны кулың белән илтә алмадың,
Мин менә бот арама кыстырып та илтә аламын".
Балда биягә менеп атланды,
Чабып китте, – диңгез буен тузан каплады.

Шүрләп диңгезгә чумды җен,
Сөйләде Балданың җиңүен.
Башка җеннәр дә җыелып килделәр,
Чара юк, оброк җыеп бирделәр.
Кайта Балда капчыгын асып,
Тамак кыргалап, эре басып.
Күрү белән попның коты очты,
Бикәсе артына посты.
Балда аны тапты шунда ук,

Хезмәт хакын түләми чара юк.
Маңгаен Балдага якын китерде;
Бер чиертүдән поп түшәмгә сикерде.
Балда тагын бер чиертеп алды, —
Поп телдән калды.
Балда чиертте өченче кабат, —
Акылдан язды карт.
Балда кабатлый аны тиргәп:
"Йөрмә арзанны гына эзләп!"



ББК 84(Р-Тат) —5
П89

КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫНА

Пушкин Александр Сергеевич

СКАЗКА О ПОПЕ И О РАБОТНИКЕ ЕГО БАЛДЕ

(на татарском языке)

ИБ № 6800

Салих Баттал тәрҗемәсе
Мөхәррире *Ф. Зыятдинова*
Художество мөхәррире *Р. Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире *Ф. Кәбирова*
Корректоры *Г. Зиннәтуллина*

Нәшрияткa 0201 нче номерлы лицензия
1997 елның 22 августында бирелгән.

Җыярга тапшырылды 20.11.97. Басарга кул куелды 23.01.98. Форматы $60 \times 90^1/_8$. Офсет кәгазе № 1. "Татар-Кудряшов" гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 2,0. Шартлы буяу-оттиск 10,0. Нәшер-хисап табагы 2,81.
Тиражы 5000 экз. Заказ Ф-71.

Татарстан китап нәшрияты. 420503. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420503. Казань, ул. Баумана, 19.

"Полиграфия-нәшер комбинаты" берләштерелгән Дәүләт предприятиесе.
420503. Казан, Бауман ур., 19.

$П \frac{4803560102-004}{М132(03)-98} 80-97$

ISBN 5-298-00727-9

© Рәсемнәр. Татарстан китап нәшрияты, 1998.

Рәссамы
Колмогорцева И. К.



КАЗАН

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ

1998